ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 23 марты**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 624**

2017 елның I кварталына «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча торак урындагы гомуми мәйданның 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 22 декабрендәге «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2017 елның беренче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм 2017 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 1003/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча 2017 елның I кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының хакын 35 079 (утыз биш мең җитмеш тугыз) сум күләмендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин